# Кырынды авылында яшәүче Гараева Мәрзия апа истәлекләреннән. «Үзәк өзгеч хатирәләр.»
(хәзер инде мәрхүмә)

1941 нче елның июнь ае. Мин 20 яшьлек кыз. Безгә уракка чыгарга кәгазь өләштеләр. Анда «Һәр кешегә 1 га. урак урырга» -дип язылган. Ул елны ашлык бик нык уңды. Басуда урак урганда Җәүхәрия йөгереп килеп: «Сугыш башланган» - дип кычкырды. Без уракларны ташлап өйгә кайттык, өйдә радиодан да сугыш турында Левитан сөйли иде.

Әтине 22 июнь көнне сугышка озаттык, аңа әни икмәк пешереп бирде. Без әтидән 1 капчык солы оны һәм 2 буй утын белән калдык. Җәйне урак урдык, җәй көне тамак тук иде. Ләкин җәй гел булмый, кышка кердек. Кыш көне базарга әни белән барып ике бәләкәй чана алдык. Урманга һәр көнне әни белән утынга бардык. Бер чананы өйгә, икенче чана утынны ипигә, бәрәңгегә алыштыра идем. Беренче елны бик авыр булды.1942 нче елның җәендә Ятчә авылына урак урырга җибәрделәр, мин аннан бик күп ашлык алып кайттым. Һәр якшәмбе Ятчә базарына хәер сорарга бара идем. «Сугыш еллары бик авыр булды. Бу сугыш бүтән кабатланмасын иде, яралар әле дә сызлый», - дип бетерде ул сүзен.

«Сугыш башланганда миңа нибары 15 яшь иде» - дип сөйләде Садыков Касыйм абый. Ул көнне мин нидәндер шомланып уяндым. Тышка чыксам, Кеше авызында сугыш дигән куркыныч сүз. Соңрак эти белән әни: «Сугыш баш - ланган улым, сугыш» - дип әйттеләр.

Авылдан күп кенә ир – атлар сугышка китте. Авыл бушап калды: бары тик хатын – кызлар һәм балалар. Мине тимер-челеккә эшкә куйдылар, соңрак Әгерҗегә укырга җибәрделәр. Аннан соң инде мин агач эшенә тотындым. 1941 нче елның кышы бик салкын булды. Көн саен диярлек урман – га бардык. Җәй көннәре дә күңелле булмады: чөнки халык ач, хайваннар да тилмерә. Атларга солы җитми. Без Габдулла белән Әгерҗегә керосинга йөрдек. Атлар җигеп китәбез. Ашарга бәрәңге һәм сөт. кайтканда атлар авыр йөкне тарта алмыйча егылалар иде. Аларны ял иттереп әз - мәз печән ашатабыз. Кайта – кайта кич җитә, кайчак кунып калган чаклар да була. Соңарсак, колхоз рәисе ачулана.

«Без күргәннәрне сез күрмәсәгез иде», - дип авыр сулап бетерде ул сүзен.

Җәйге матур иртә иде. Ул көнне без әтәч кычкыруына түгел, ә «сугыш чыкты»- дигән хәтәр ачы тавышка уяндык. Бу ямьле иртә әллә нинди шыксыз, ямьсез, кара булып күренде. Күпләргә бу хәтәр хәвеф аяз көндә яшен суккандай булды. Кеше башта берни аңламады, йөрәге аның ташка әйләнде, тере мәет кебек ул әле монда, әле тегендә ташланды. Һәм телендә аның «сугыш чыкты, сугыш…» - дигән сүзләр генә булды. Нинди олы хәсрәт иде бу. Анага улын, хатынына – ирен, кызга сөйгән ярын, этисен, хәтта бабасын да озатырга туры килде. Бу вакыйга күпләрне өнсез калдырды, күзләргә яшь тулды. Әйе, бик шомлы иде бу көн. Бары тик табигать кенә үзгәрмәде: кояш элеккечә көлде, шул ук чәчәкләр, агачлар. Ләкин болар бары да кешегә әллә нинди ят булды. Бала – чагалар гына һаман уйнауларын дәвам иттеләр. Ул иртәне кешеләр ни генә кичермәделәр. «Ни өчен, ни өчен сугыш» - дигән сүзләр күп яңгырады ул иртәдә. Ләкин бу әле сугышның беренче көне иде. Әле авырлыкларның нинди булачагын күз алдына китерү дә авыр иде.

Закирова Гафия.
70 яшь